## Дәреснең темасы:

# “Кушма жөмлә эчендәге тыныш билгеләрен кабатлау”

# Дәреснең максаты:

*Белем бирү максаты (укытучы өчен):* кушма җөмлә эчендәге тыныш билгеләрен дөрес куеп яза белергә өйрәтү;

*(укучы өчен):* универсаль укыту гамәлләренең беренче төрен тормышка ашыру: укытучы куйган максаттан чыгып, үз эшчәнлекләрен планлаштыру һәм аларны тормышка ашыру юлларын, чараларын эзләү, табу, сынап карау, нәтиҗә ясау.

*Үстерү максаты:* кушма җөмлә эчендә тиешле тыныш билгеләрен кую күнекмәсен үстерү;әдәби телдә дөрес һәм образлы итеп сөйләү телен үстерү, укучыларның сүзлек байлыгын арттыру.

*Тәрбия максаты:*укучыларда янәшәдәге кешеләргә игътибарлылыкны арттыру һәм пөхтәлек тәрбияләү.

# Карточка белән эш

**<u>Бирем:тиешле тыныш билгеләрен куеп язарга</u>.**

1. Язмыш сынаулары бу матур гаиләне дә читләтеп үтми ... аларның бәхетле еллары озакка сузылмый.
2. Сараның җырлавын дуслары бик яраталар ... ә Газиз аның тавышыннан тәмам сихерләнә.
3. Яшьлегең тырыш булса ... картлыгың тыныч була.
4. Кемнең телендә ни булса ... күңелендә шул була.
5. Мин беләм ... сез үзегезне генә кайгыртa торган кеше түгел.
6. Мин шуны сизәм ... Нурсөя мине сүзсез дә аңлый .
7. Җир ап-ак булган ... әйтерсең аңа ак юрган ябылган.

# Схемага туры килгән җөмләнең номерын язарга

1. (... – са), [ ].
2. [ ],[ ].
3. (..ни), [ шул ].
4. [ шуны]: ( ).
5. [ ], ( әйтерсең...) .
6. [ ]: ( ).
7. [ ],ә[ ].

# Бирелгән схемаларга нинди тыныш билгесе куярсың?

1)[  ялгызак мөнәсәбәтле сүз] ? (......).

2)[    ]  ? [    ].

3)[….] ? (ияртүче теркәгеч).

4)(......) ?  [  ялгызак мөнәсәбәтле сүз] .

5)(...-са да) ? [   ].

# Өйгә эш

Әле генә эшләгән биремдәге схемаларга туры килерлек итеп,җөмләләр төзеп язарга.